СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

29.12.2022 № 28/3

На №__________ от______________

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23-25 статьялары, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча 2022 елның 14 декабрендәге халык тыңлаулары беркетмәләре, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында 2022 елның 14 декабрендәге бәяләмәләр, Тукай муниципаль районы уставынигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең генераль планын расларга.
2. Тукай муниципаль районы Иске Дөрешавыл җирлеге Советының 2014 елның 12 декабрендәге 30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең генераль планын гамәлдән чыгарырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Р.И. Закиров